СОВЕТ
КУРНАЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
КӨРНӘЛЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ** Коры Көрнәле ав. **КАРАР**

08.04.2026 № 18

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы «Көрнәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2014 елның 19 ноябрендәге 80 номерлы «Көрнәле авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү, шулай ук Көрнәле авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакындагы Нигезләмәне раслау турында» карарының үз көчен югалтуын тану турында**

«Россия Федерациясе Президентының кайбер актларын үзгәртү һәм аларның үз көчләрен югалтуын тану турында» Россия Федерациясе Президентының 2025 елның 31 декабрендәге 1009 номерлы Указына туры китереп,

**Көрнәле авыл җирлеге Советы карар бирде:**

1. Норматив хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы «Көрнәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының түбәндәге карарларының үз көчен югалткан дип танырга:

- «Көрнәле авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү, шулай ук Көрнәле авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакындагы Нигезләмәне раслау турында» 19.11.2014ел, №80 карары;

- «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Көрнәле авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Көрнәле авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакындагы Нигезләмәне раслау турында» Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Көрнәле авыл җирлеге Советының 19.11.2014ел,№80 карарына үзгәрешләр кертү турында» 15.11. 2023 ел, № 55 карары;

- «Көрнәле авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү, шулай ук Көрнәле авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакындагы Нигезләмәне раслау турында» Советның 19.11.2014ел, №80 карарына үзгәрешләр кертү турында» 27 .06.2024ел, № 69 карары.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында (https://alekseevskiy.tatarstan.ru/), Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Көрнәле авыл җирлеге Башлыгы, Совет рәисе** **Д.Б.Казакова**

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ КУРНАЛИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА р05-11124/13 СОВЕТ КУРНАЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ